**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«08» 09 2025 ел Яр Чаллы ш. № 2978

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 гыйнварендәге 4 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 декабрдәге 5534 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыфаларын башкаручы Г.Ә. Галимова

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «08» 09 2978 ___ номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 сентябреннән ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ромашка» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
| --- | --- | --- | --- |
| 1 | «Дежур төркем» | 834,28 | 1 ай (атнага 7,5 сәгать) |

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы мөдире ______________ Т.В. Гусева

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. «Дежур төркем» - балаларны карауга һәм тәрбияләүгә юнәлдергән. Әлеге хезмәт 2 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 56 кв.м., балалар саны - 15. Хезмәтләр күрсәтү формасы – төкемле. Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы – 1 ай (атнага 7,5 сәгать).

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы мөдире ____________ Т.В. Гусева

ДЕТСКИЙ САД "РОМАШКА"
ОГРН 1041601371417
ИНН 1639019374